МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 июнь 2020 ел №Мл 197

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр турында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турындагы мәгълүматка керүне тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 4 бүлек нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләрне (алга таба – таләпләр) кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2020 елның 10 июнендәге
М 197 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан файдалануны тәэмин итүнең технологик, программа һәм лингвистик чараларына таләпләр

1. Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла торган мәгълүмат:

1) мәгълүматтан файдаланучыларга алу, танышу һәм файдалану өчен, шулай ук мәгълүмат системалары тарафыннан автоматик (кеше катнашыннан башка) эшкәртү өчен, мәгълүмат белән танышу яки аны башкача файдалану өчен түләү алмыйча һәм башка чикләүләрсез, тәүлек буе һәркем файдалана алырлык булырга тиеш;

2) мәгълүматтан файдаланучыларга, аны мәгълүматтан файдаланучының техник чараларына кую файдаланучы тарафыннан программалар белән тәэмин итү хокукына ия булучы белән, мәгълүматтан файдаланучыдан түләү алуны күздә тотучы, лицензион яки башка үзара килешү төзүне таләп итә торган программалар белән тәэмин итүне файдаланмыйча, һәркем файдалана алырлык булырга тиеш;

3) шифрланган булмаска яки мәгълүматтан файдаланучының, веб-күзәтүчедән тыш, башка программалар белән тәэмин итүне яки техник чаралар файдаланмыйча, аның эчтәлеге белән танышуын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми торган башка чаралар белән керүдән сакланган булырга тиеш. Рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге мәгълүматтан файдаланучылардан теркәлүне яки алар тарафыннан шәхси мәгълүматлар бирүне таләп итү, шулай ук алар тарафыннан лицензион яки башка үзара килешүләр төзүне таләп итү шарты белән чикләнә алмый.

2. Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайт эшендә өзеклеклекләрнең суммар дәвамлылыгы айга 4 сәгатьтән артмаска тиеш (каршы тора алмаслык хәлләр белән бәйле өзеклекләрдән тыш). Мәгълүматтан файдаланучыларга рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге бирми торган планлы техник эшләр үткәрергә кирәк булганда, бу хакта хәбәр рәсми сайтның баш битендә эшләр башланганчыга кадәр бер тәүлектән дә соңга калмыйча куелырга тиеш.

Мәгълүматтан файдаланучыларның рәсми сайтка керә алмавына китерүче техник җитешсезлекләр, программалар белән тәэмин итүдә җитешсезлекләр яки башка проблемалар килеп чыккан очракта, файдалану мөмкинлеген туктатуның сәбәбе, датасы һәм вакыты, шулай ук мәгълүматтан файдалану мөмкинлегенең

яңадан башлану датасы һәм вакыты күрсәтелгән белдерү урнаштырылырга тиеш.

3. Текст рәвешендәге мәгълүмат рәсми сайтта фрагментларын веб-күзәтү чаралары белән эзләү һәм күчермә ясау мөмкинлеген тәэмин итә торган форматта («гипертекст форматы») урнаштырыла.

4. Программалар белән тәэмин итү һәм рәсми сайттан файдалануны тәэмин итүнең технологик чаралары, шулай ук анда урнаштырылган мәгълүматның форматлары түбәндәгечә булырга тиеш:

1) файдаланучыларның рәсми сайтта урнашкан мәгълүматка тиз арада һәм иркле керүен тәэмин итәргә. Рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматтан файдалану, мәгълүматтан файдаланучылар тарафыннан билгеле бер веб-күзәтүчеләрдән файдалануны яки мәгълүматтан файдаланучыларның техник чараларына рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматка керү өчен махсус ясалган программалар белән тәэмин итү җайланмалары куюны таләп итү шарты белән чикләнә алмый;

2) мәгълүматтан файдаланучыларга рәсми сайтта урнаштырылган барлык текстлы мәгълүматны каршылыксыз эзләү һәм алу мөмкинлеге бирергә, сайтта бастырып чыгарылган барлык документлар арасыннан документны аның реквизитлары буенча эзләүне дә кертеп;

3) мәгълүматтан файдаланучыларга рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматны Интернет челтәрендә мәгълүматны автоматлаштырылган җыю чаралары, шул исәптән эзләү системалары белән эзләү һәм алу мөмкинлеге бирергә;

4) мәгълүматтан файдаланучыларга сайттан, шул исәптән клавиатура ярдәмендә, аерым клавишаларны билгеле бер вакыт басып тормыйча яки кертүнең билгеле бер эзлеклелеген сакламыйча, берьюлы берничә клавишага басу мөмкинлеге, шулай ук рәсми сайттан төрле кертү һәм чыгару җайланмалары, шул исәптән сенсорлы экраннар кулланып, файдалану мөмкинлеге бирергә;

5) мәгълүматтан файдаланучыларга мәгълүматны урнаштыру датасын һәм вакытын билгеләү мөмкинлеге бирергә;

6) гамәлдәге рәсми сайтның, рәсми сайтны эксплуатацияләүнең соңгы 6 аенда теркәлгән мәгълүматтан файдаланучыларның, сайтка тәүлеклек максималь мөрәҗәгать итү саныннан ике тапкырга артык сайтка мөрәҗәгать итү саны белән билгеләнә торган эш күләме белән эшли алуын тәэмин итәргә; яңа ясалган яисә 6 айдан кимрәк эшләүче рәсми сайтка – айга 10 000 мөрәҗәгатьтән ким булмаган эш күләме;

7) рәсми сайтның барлык битләрендә Интернет челтәрендә статистика җыюның һәркем файдалана алырлык системалары тарафыннан бирелә һәм мәгълүматтан файдаланучының битләргә керү фактын фиксацияләүне тәэмин итә торган программа коды («керү счетчигы») урнаштыру юлы белән рәсми сайтның барлык битләренә керүне исәпкә алуны тәэмин итәргә. Рәсми сайтларда, аның турындагы мәгълүматлар электрон хисаплау машиналары өчен Россия программаларының бердәм реестрына һәм мәгълүматлар базасына кертелгән программалар (программа коды («керү счетчигы») белән тәэмин итүне куллану рөхсәт ителә.

8) Интернет челтәрендә рәсми сайтка керү (рәсми сайтка керү һәм уникаль керүчеләр, аның аерым битләренә сәгатьләр, көннәр һәм айлар буенча керү саны) турында җыелма мәгълүматларны түләүсез ачуны, соңгы өч ел өчен күрсәтелгән җыелма мәгълүматларны саклауны һәм аларның мәгълүматтан файдаланучылар өчен һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итәргә;

9) «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматка керүне тәэмин итү хакында» 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүмат, экран диагоналенең үлчәме 48 миллиметрдан артык булган электрон хисаплау машиналарында файдалану өчен билгеләнгән программалар белән тәэмин итүне файдаланып уку өчен һәркем файдалана алырлык булырга тиеш;

10) рәсми сайттан файдаланганда мәгълүматтан файдаланучыга, экран диагонале төрле үлчәмдә булган электрон хисаплау машиналары ярдәмендә файдалану өчен, сайтның Таләпләрнең әлеге пунктындагы 9 пунктчаның нигезләмәләрен исәпкә алып оптимальләштерелгән версияләрен сайлау мөмкинлеге бирелергә тиеш.

5. Рәсми сайтның навигация чаралары түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) рәсми сайтта урнаштырылган барлык мәгълүмат мәгълүматтан файдаланучылар өчен, рәсми сайтның баш битеннән башлап, гиперсылтамаларга бер-бер артлы күчү юлы белән һәркем файдалана алырлык булырга тиеш;

2) мәгълүматтан файдаланучыга рәсми сайтның структурасы һәм бу структурада чагылдырылган битнең урнашу урыны турында күрсәтмә мәгълүмат бирелергә тиеш;

3) рәсми сайтның һәрбер битендә урнашырга тиеш: баш меню, баш биткә сылтама, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең исеме;

4) битләрдәге исемнәр һәм язмалар әлеге битнең эчтәлеген (билгеләнешен), агымдагы бүлекнең һәм чагылдырылган документның исемен тасвирларга тиеш; аның эчтәлеген тасвирлаучы битнең исеме веб-күзәтүче тәрәзәсенең исемендә чагылырга тиеш;

5) Интернет челтәрендәге һәрбер битнең текстлы адресы (ресурсның универсаль күрсәткече, URL) битнең сайтның логик структурасындагы торышын чагылдырырга һәм эчтәлегенә (билгеләнешенә) туры килергә тиеш, шулай ук текстлы адреста транслитерациянең стандарт кагыйдәләре файдаланылырга тиеш.

6. Рәсми сайтта урнаштырылган мәгълүматны саклау максатында, түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш:

1) рәсми сайтта яңалыклар мәгълүматын һәм структур бүлекчәләр битләрендәге мәгълүматны урнаштыру, үзгәртү һәм бетерү буенча эш итүләрне исәпкә алуны тәэмин итәргә, үзгәрешләрнең төгәл вакытын, эчтәлеген һәм рәсми сайтта үзгәрешләрне гамәлгә ашыручы хезмәткәр турында мәгълүматны теркәп барырга мөмкинлек бирә торган программалар белән тәэмин итү һәм рәсми сайтны алып баруның технологик чаралары ярдәмендә башкарылган операцияләрне исәпкә алуның электрон журналларын алып бару;

2) рәсми сайтта урнаштырылган барлык мәгълүматны һәм операцияләрне исәпкә алуның электрон журналларын, аларны кире торгызу мөмкинлеген тәэмин итү өчен, атна саен резерв материаль йөрткечкә күчермәсен ясау;

3) мәгълүматны юкка чыгудан, модификациядән һәм аннан файдалану мөмкинлеген блокировкалаудан, шулай ук мондый мәгълүматка карата башка хокуксыз эш итүләрдән саклау;

4) рәсми сайтта урнаштырылган барлык мәгълүматның һәм операцияләрне исәпкә алу электрон журналларының резерв материаль йөрткечләрдәге күчермәләрен саклау – бер елдан ким түгел.

7. Рәсми сайтта мәгълүмат рус һәм татар телләрендә урнаштырыла.

Чит ил юридик һәм физик затларның исемнәре, шулай ук чит ил рәсми тамгалары тиешле чит ил алфавитын файдаланып күрсәтелә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

Ф.И. Андреева